РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ СТАРОИКШУРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422066, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Старая Икшурма, ул. Ленина, д.17
тел. (84362) 41-6-47

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ИКШЕРМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422066, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Иске Икшермә авылы, Ленин урамы, 17 йорт
тел. (84362) 41-6-47

e-mail: sik.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
09.11.2020

КАРАР
№ 10

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 28 нче апрелендә кабул ителгән 10 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында»

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советы

Карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 28 нче апрелендә кабул ителгән 10 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладын 11 498 сум күләмендә расларга.»;

1.2. Карарга 1 нче кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның гамәлен 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына 2020 елның 1 октябреннән, әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, яңа штат расписаниеләрен расларга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru

Иске Икшермә авыл җирлеге башлыгы урынбасары: А.И.Биккинин

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Иске Икшермә авыл җирлеге Советының
2020 елның 9 ноябре, № 10 карарына

Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының акчалата бүләкләре күләме

| Вазыйфалар исемнәре акчалата бүләк күләме (сумнарда) | акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Авыл җирлеге башлыгы | 15759 |
| Депутатлар | 11498 |
| Сайланулы вазыйфаи затлар | 11498 |